**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 15 июль | № 513

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 апрель, 233 нче; 2015 ел, 11 июнь, 441 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен;

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендәге кечкенә фермалар төзүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган 2015 елга агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган финанслау күләмнәрен бүлүдә:

4 нче пункттагы «5 200,0» саннарын «9 764,0» саннарына алыштырырга;

12 нче пункттагы «463 555,6» саннарын «533 555,6» саннарына алыштырырга;

24 нче пункттагы «35 000,0» саннарын «45 000,0» саннарына алыштырырга;

30 нчы пункттагы «11 900,0» саннарын «13 597,299» саннарына алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 32 – 33 нче пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «32. | 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны | 50 000,0 |

| | | |
|---|---|---|
| | сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | |
| 33. | 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендәге кечкенә фермалар төзүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 70 000,0»; |

«Барлыгы» юлындагы «6 009 143,6» саннарын «6 215 404,899» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үсемлекчелек өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибенең 13 нче пунктындагы «2014 елның көзендә һәм (яки) 2015 елның язында» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сатып алынган оригиналь һәм затлы орлыклар буенча чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«туфраклы сортлы тикшерү үткәрү.»;

түбәндәге эчтәлекле $12^1$ нче пункт өстәргә:

«$12^1$. Авыл хуҗалыгы хайваннары сатып алу чыгымнарын каплау өчен гаилә фермаларына субсидияләр мөгезле эре терлекнең, дуңгызларның, сарыкларның, кәҗәләрнең бер килограмм тере авырлыгына 27,0 сум исәбеннән чыгып бирелә.

Туфраклы сортлы тикшерү үткәрү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр туфраклы сортлы тикшерү үткәрелергә тиешле үрнәккә 6500,0 сум исәбеннән чыгып бирелә.»;

түбәндәге эчтәлекле $15^1$ нче пункт өстәргә:

«$15^1$. Әлеге Тәртипнең $12^1$ нче пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Идарәгә түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

Министрлык раслаган форма буенча туфраклы сортлы тикшерү үткәрү планы;

Министрлык раслаган форма буенча туфраклы сортлы тикшерү үткәрү буенча башкарылган эш турында хисап;

бирелергә тиешле субсидияләр турында Министрлык раслаган форма буенча белешмә-исәп-хисап.»;

күрсәтелгән Тәртипкә теркәлгән кушымтада:

«Сортларга экологик зона сынавы» юлындагы «4000,0» саннарын «2000,0» саннарына алыштырырга;

«Орлыкчылык хуҗалыкларын стимуллаштыру» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Туфраклы сортлы тикшерү үткәрү | 2000,0»; |

әлеге карар белән расланган 2015 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктта «хайваннарны ясалма орлыкландыру операторларына» сүзләреннән соң «, теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыкларына» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктта:

дүртенче абзацтагы «һәм ит» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче абзац өстәргә:

«2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата ит өчен үстерелгән мөгезле эре терлекнең шартлыча бер башына – 2000,0 сум исәбеннән чыгып;»;

9 нчы пунктта «50,0» саннарын «60,0» саннарына алмаштырырга;

14 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нәсел үрчеткеч нәселле ата дуңгызларның һәм (яки) нәсел үрчеткеч үгезләрнең күп баш саны булу»;

16 нчы пунктның беренче, ундүртенче һәм унбишенче абзацларында тиешле килешләрдәге «авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре,» сүзләреннән соң тиешле килешләрдәге «теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге агросәнәгать комплексы оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыклары,» сүзләрен өстәргә;

24 нче пунктның беренче абзацындагы «2015 елда» сүзләрен «2013 – 2015 елларда» сүзләренә алыштырырга;

25 нче пунктның җиденче абзацында «хайваннарны орлыкландыру буенча» сүзләреннән соң «теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге агросәнәгать комплексы оешмаларының, индивидуаль эшмәкәрләрнең, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыкларының» сүзләрен өстәргә;

26 нчы пунктта «хайваннарны орлыкландыру буенча» сүзләреннән соң «теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге агросәнәгать комплексы оешмасы, индивидуаль эшмәкәр, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыгы белән» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтаның таблицасында:

1 нче пунктта «57 800,0» саннарын «61 800,0» саннарына алыштырырга;

2 нче пунктта «12 000,0» саннарын «9 335,0» саннарына алыштырырга;

3 нче пунктта «13 500,0» саннарын «10 665,0» саннарына алыштырырга;

19 нчы пунктта «15 000,0» саннарын «16 500,0» саннарына алыштырырга;

20 нче пунктта «90 000,0» саннарын «160 000,0» саннарына алыштырырга;

«Барлыгы» юлында «463 555,6» саннарын «533 555,6» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы кадрларына дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын финанслау тәртибендә:

2 нче пунктта «авыл хуҗалыгы җитештерүендә» сүзләреннән соң «һәм (яки) кулланучылар кооперациясе оешмаларында» сүзләрен өстәргә;

3 нче пунктның бишенче абзацында «авыл хуҗалыгы оешмасы белән» сүзләреннән соң «һәм (яки) кулланучылар кооперациясе оешмасы белән» сүзләрен,

«авыл хуҗалыгы оешмасында» сүзләреннән соң «һәм (яки) кулланучылар кооперациясе оешмасында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 7[1] нче пункт өстәргә:

«7[1]. Авыл җирлегендә эшләүче яшь белгечләр арасында һөнәри осталык буенча республика конкурсында җиңүчеләргә 66,0 мең сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган акча бирелә.

Бер тапкыр түләнә торган акчаны бирү өчен Министрлыкның авыл җирлегендә эшләүче яшь белгечләр арасында һөнәри осталык буенча республика конкурсы нәтиҗәләрен раслау турындагы карары нигез булып тора. Акчаны алучыларның шәхси банк исәпләренә акчаны күчерү, Министрлык карарга кул куйган көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган 2015 елда ветеринария-санитария савыктыруы чараларын финанслау тәртибендә:

3 нче пунктка «, шулай ук хуҗалыкларны хайваннар туберкулезыннан савыктыру буенча башкарылган эшләрнең исемлеген һәм күләмнәрен раслый.» сүзләрен өстәргә;

5 нче пунктта «һәм төяп җибәрү буенча» сүзләреннән соң «, хуҗалыкларны хайваннар туберкулезыннан савыктыру эшләрен башкару буенча» сүзләрен, «ветеринария билгеләнешендәге товарлар сатып алуга акча бүлүне» сүзләреннән соң «һәм хуҗалыкларны хайваннар туберкулезыннан савыктыру эшләрен башкаруны» сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктта «һәм төяп җибәрү буенча» сүзләреннән соң «, хуҗалыкларны хайваннар туберкулезыннан савыктыру эшләрен башкару буенча» сүзләрен, «дәүләт контракты,» сүзләреннән соң «башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актлары,» сүзләрен өстәргә;

бу Тәртипкә теркәлгән кушымтаның таблицасында:

41 нче пункттагы «205,0» саннарын «10 205,0» саннарына алыштырырга;

«Барлыгы» юлындагы «35 000,0» саннарын «45 000,0» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенең 5 нче пунктында «2015 елның 17 гыйнварыннан 28 мартына кадәрге чорда» сүзләрен «2015 елның 17 гыйнварыннан 8 маена кадәрге чорда» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәк җитештерүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктта «он сатып алуга бәйле» сүзләреннән соң «һәм (яки) он җитештерүгә бәйле» сүзләрен өстәргә;

6 һәм 7 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидияләр түбәндәге предприятиеләргә бирелә:

сатып алынган онны кулланучы, – 1 сортлы бер килограмм бодай онының базар кыйммәте белән фондның 1 сортлы бер килограмм бодай онының билгеләнгән бәясе арасындагы аерма буларак, ләкин бер килограмм бәясен 4 сумнан да арттырмыйча;

үзләре җитештергән онны кулланучы, – 1 сортлы бер килограмм бодай онының билгеләнгән үзкыйммәте белән фондның 1 сортлы бер килограмм бодай онының билгеләнгән бәясе арасындагы аерма буларак, ләкин бер килограмм бәясен 4 сумнан да арттырмыйча.

7. Субсидияләр алу өчен предприятиеләр Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресларын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

бер айга социаль икмәк (1 сортлы бодай оныннан һәм 1 сортлы арыш һәм бодай оныннан кушылып пешерелгән икмәк, яраклылык вакыты 10 көннән ким булган) җитештерү күләме турында мәгълүмат;

бирелергә тиешле субсидия турында Министрлык раслаган форма буенча белешмә-исәп-хисап.

Сатып алынган онны кулланучы предприятиеләр шулай ук түбәндәгеләрне кертә:

1 сортлы бодай оны кайтарту турында шартнамә;

он сатып алуга товар-транспорт йөкнамәсен;

он өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәсен;

Үзләре җитештергән онны кулланучы предприятиеләр шулай ук түбәндәгеләрне кертә:

ашлык кайтарту турында шартнамә;

ашлык сатып алуга товар-транспорт йөкнамәсен;

ашлык өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәсен;

онны җитештерүгә тапшыру турында йөкнамә;

социаль икмәк җитештерү өчен 1 сортлы бодай онының үзкыйммәтен билгеләү исәп-хисабы.»;

әлеге карарга 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә:

«2015 елда
шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр (алга таба – хуҗалыклар, субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Хуҗалыкларга субсидияләр бирү максатлары – савым сыерларның баш санын арттыру, терлекчелек продукциясен җитештерүне арттыру һәм шул нигездә авыл халкының эш белән тәэмин ителешен һәм керемнәрен күтәрү.

4. 2015 елда хуҗалыкларга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча финанслау лимитларын бүлү бу Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендә 2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата шәхси ярдәмче хуҗалыклар исәбе алып барыла торган хуҗалык кенәгәләрендә күрсәтелгән савым сыерларның баш санына пропорциональ рәвештә гамәлгә ашырыла.

5. Субсидияләр хуҗалыкларга мөгезле эре терлектән булган яңадан сатып алынган һәр тана өчен 15,0 мең сум исәбеннән чыгып бер тапкыр түләнә, ләкин бер хуҗалыкка мөгезле эре терлектән булган биш танадан да арттырмыйча һәм сатып алынган хайваннарның кыйммәтен 50 проценттан да арттырмыйча бирелә.

6. Субсидия алу өчен хуҗалыклар авыл яки шәһәр җирлекләре башкарма комитетларына, республика карамагындагы шәһәр нигезендә оештырылган шәһәр җирлекләреннән тыш (алга таба – Башкарма комитетлар), түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын, почта адресын һәм субсидия алган көннән 5 ел дәвамында мөгезле эре терлектән булган сатып алынган таналарны саклау йөкләмәсен күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

2015 елда авыл хуҗалыгы оешмаларыннан мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарын раслаучы документлар (сату-алу шартнамәләренең, исәп-фактураларның, товар йөкнамәләренең, түләү документларының, ветеринария белешмәләре һәм шәһадәтнамәләренең, мөгезле эре терлектән булган сатып алына торган таналарның исемен, яшен күрсәтеп, авыл хуҗалыгы хайваннарын сатып алу өчен кабул итү-тапшыру актының төп нөсхәләре һәм күчермәләре; тикшергәннән соң төп нөсхәләр гариза бирүчегә кире кайтарыла, күчермәләре тиешле авыл яки шәһәр җирлегенең Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана);

2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата һәм мөгезле эре терлектән булган таналар сатып алганнан соң, шәхси ярдәмче хуҗалыклар исәбе алып барыла торган хуҗалык кенәгәсеннән тиешле авыл һәм шәһәр җирлеге башлыгы тарафыннан расланган өземтә;

мөгезле эре терлектән булган сатып алынган таналар күпләп үлгән очракта яисә аларны авыру сәбәпле суйган очракта, хуҗалыклар, кабул ителгән йөкләмәнең вакыты чыкканга кадәр, Башкарма комитетларга ветеринария белешмәләрен һәм терлекне бракка чыгару актларын тиешле тәртиптә кертәләр.

7. Башкарма комитетлар (килешү буенча):

субсидияләр бирү турындагы гаризаларны алар кергән көндә журналда терки, журналның бит саннары куелган, тегелгән һәм мөһер белән расланган булырга тиеш;

гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә:

бу Тәртипнең 6 нчы пункты нигезендә тапшырылган документларны карый;

субсидияләр бирү өчен түләү ведомостьларын һәм Министрлык раслаган форма буенча хуҗалыкларга бирелергә тиешле субсидияләр турында белешмә-исәп-хисаплар тутыра һәм аларны Министрлыкның муниципаль районнардагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр) кертә.

Субсидияләр алуга документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы комплектын кертмәү;

хуҗалыкның әлеге Тәртип шартларына туры килмәве.

8. Идарәләр документлар тапшырылган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә:

бу Тәртипнең 7 нче пункты нигезендә тапшырылган документларны карый һәм субсидияне бирү турында яки субсидияне бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә;

күрсәтелгән документлар нигезендә муниципаль районнар арасында субсидияләр алучылар буенча белешмәләрне гомумиләштерә, Министрлык раслаган форма нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча хуҗалыкларга бирелергә тиешле субсидияләр турындагы җыелма белешмә-исәп-хисапларны тутыра һәм Министрлыкка кертә.

Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы комплектын кертмәү;

хуҗалыкның әлеге Тәртип шартларына туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитыннан акча калмау.

9. Министрлык хуҗалыклар белән Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешүләр төзи.

10. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм акчаны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлекләрендә ачылган шәхси исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелгән җыелма белешмә-исәп-хисаплар бюджет акчасын күчерү өчен нигез булып тора. Бюджет акчасы шәхси исәпләренә күчерелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә Идарәләр субсидияләрне хуҗалыкларның банк исәпләренә күчерә.

11. Әлеге Тәртип нигезендә 2015 елның 1 октябренә кадәр үзләштерелмәгән бюджет акчасы булган очракта, Министрлык Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бу Тәртипкә теркәлгән кушымта белән күздә тотылган акчаны яңадан бүлү турында тәкъдимнәрен кертә.

12. Бирелгән субсидияләр билгеләнгән субсидияләрдән максатка яраксыз файдалану һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм

документлар кертү фактларын ачыклау буенча Идарәнең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keremенә кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидияләр бирү турындагы килешүләр белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр субсидияләр алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Бу Тәртипнең 12 нче һәм 13 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә үз ирекләре белән кире кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

15. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибенең субсидияләр алучылар тарафыннан үтәлешен тикшерүне законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

16. Башкарма комитетлар, Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелә торган документларның һәм хуҗалыклар тапшыра торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә тиешле затларга һәм җитәкчеләргә йөкләнә.

17. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча финанслау лимитларын бүлү

| Т/с | Татарстан Республикасы муниципаль районы исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 975,0 |
| 2 | Азнакай | 1 335,0 |
| 3 | Аксубай | 1 860,0 |
| 4 | Актаныш | 2 250,0 |
| 5 | Алексеевск | 1 125,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 6 | Әлки | 1 200,0 |
| 7 | Әлмәт | 870,0 |
| 8 | Апас | 1 020,0 |
| 9 | Арча | 2 595,0 |
| 10 | Әтнә | 1 215,0 |
| 11 | Баулы | 960,0 |
| 12 | Балтач | 2 325,0 |
| 13 | Бөгелмә | 555,0 |
| 14 | Буа | 1 455,0 |
| 15 | Югары Ослан | 210,0 |
| 16 | Биектау | 1 020,0 |
| 17 | Чүпрәле | 2 295,0 |
| 18 | Алабуга | 345,0 |
| 19 | Зәй | 810,0 |
| 20 | Зеленодольск | 810,0 |
| 21 | Кайбыч | 720,0 |
| 22 | Кама Тамагы | 795,0 |
| 1 | 2 | 3 |
| 23 | Кукмара | 2 175,0 |
| 24 | Лаеш | 405,0 |
| 25 | Лениногорск | 660,0 |
| 26 | Мамадыш | 1 710,0 |
| 27 | Менделеевск | 345,0 |
| 28 | Минзәлә | 1 185,0 |
| 29 | Мөслим | 1 635,0 |
| 30 | Түбән Кама | 780,0 |
| 31 | Яңа Чишмә | 900,0 |
| 32 | Нурлат | 1 935,0 |
| 33 | Питрәч | 600,0 |
| 34 | Балык Бистәсе | 1 260,0 |
| 35 | Саба | 1 200,0 |
| 36 | Сарман | 1 425,0 |
| 37 | Спас | 1 290,0 |
| 38 | Тәтеш | 900,0 |
| 39 | Тукай | 780,0 |
| 40 | Теләче | 855,0 |
| 41 | Чирмешән | 855,0 |
| 42 | Чистай | 1 650,0 |
| 43 | Ютазы | 710,0 |
| Барлыгы | | 50 000,0»; |

әлеге карарга түбәндәге редакциядә 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендәге кечкенә фермалар төзүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен өстәргә:

«2015 елда
шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендәге кечкенә фермалар төзүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендәге кечкенә фермалар төзүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр (алга таба – хуҗалыклар, субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Хуҗалыкларга субсидияләр бирү максатлары – сөтчелек юнәлешендәге кечкенә фермалар (алга таба – кечкенә фермалар) төзү исәбеннән терлекчелек продукциясен җитештерүне арттыру, шул нигездә авыл халкының эш белән тәэмин ителешен һәм керемнәрен күтәрү.

4. Субсидияләр хуҗалыкларга подряд ысулы яки хуҗалыкларның үз көчләре белән башкарылган кечкенә фермалар төзүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен бирелә.

5. Хуҗалыкларга субсидияләр бирү шартлары түбәндәгеләр:

кимендә 8 баш сыер өчен 2015 елдан да иртәрәк булмаган вакытта төзелә башлап, бүгенге көндә төзелеп беткән яки кимендә 50 проценты әзер хәлдә булган (каркасы (нигезе, диварлары) төзелгән, идәннәре эшләнгән) кечкенә фермалар булу;

хуҗалыкта 3 һәм аннан күбрәк савым сыеры булу, һәм алар турында мәгълүмат 2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата шәхси ярдәмче хуҗалыклар исәбе алып барыла торган хуҗалык кенәгәләрендә күрсәтелгән булу.

Кечкенә ферманың проект куәте җыелма смета исәп-хисабында күрсәтелә.

6. Субсидия бер тапкыр, бары тик бер объектка һәм бер хуҗалыкка гына бирелә һәм төзелешнең җыелма смета исәп-хисабы белән күздә тотылган смета кыйммәтенең 70 процентыннан һәм субсидиянең чик күләменнән артык була алмый.

7. Субсидиянең чик күләме 200,0 мең сум тәшкил итә.

8. Субсидия алу өчен хуҗалыклар авыл җирлекләренең, шулай ук Татарстан Республикасының республика карамагындагы шәһәрләре булмаган шәһәр җирлекләренең башкарма комитетларына (алга таба – Башкарма комитетлар) түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидия бирү турындагы гаризаны;

хуҗалык башлыгының паспорт күчермәсен (гомуми белешмәләр һәм яшәү урыны турындагы бүлекләре);

хуҗалык алып бару өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенә хокукны билгели торган документларның (шаһәдәтнамә) күчермәләрен;

2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата шәхси ярдәмче хуҗалыклар исәбе алып барыла торган хуҗалык кенәгәсеннән хуҗалыкта 3 һәм аннан күбрәк савым сыеры булуны раслый торган өземтәне;

кимендә 8 баш сыер өчен төзелеп беткән яки кимендә 50 проценты әзер хәлдә булган кечкенә фермалар булу турындагы гаризаны.

9. Башкарма комитетлар (килешү буенча):

субсидияләр бирү турындагы гаризаларны алар кергән көндә журналда терки, журналның бит саннары куелган, тегелгән һәм мөһер белән расланган булырга тиеш;

хуҗалыкның гаризасын теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә:

бу Тәртипнең 8 нче пункты нигезендә тапшырылган документларны карый;

2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата шәхси ярдәмче хуҗалыклар исәбе алып барыла торган хуҗалык кенәгәсеннән хуҗалыкта 3 һәм аннан күбрәк савым сыеры булуны раслый торган өземтәне, хуҗалык алып бару өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенә хокукны билгели торган документларның (шаһәдәтнамә) күчермәләрен раслый;

кечкенә фермаларны төзүгә бәйле чараларны гамәлгә ашыру максатларында, хуҗалыклар һәм Министрлыкның муниципаль районнардагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре (алга таба – Идарәләр) белән өч яклы килешүләр төзи;

җыелма смета исәп-хисабын килештерә;

хуҗалыкларның кимендә 8 баш сыер өчен төзелеп беткән яки кимендә 50 проценты әзер хәлдә булган кечкенә фермалар булу турындагы гаризаларын алар кергән көндә журналда терки, журналның бит саннары куелган, тегелгән һәм мөһер белән расланган булырга тиеш;

күрсәтелгән гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә, урынга барып, кимендә 8 баш сыер өчен төзелеп беткән яки кимендә 50 проценты әзер хәлдә булган кечкенә фермалар булу һәм аларның гамәлдәге торышы турында акт төзи һәм документларны Идарәләргә кертә.

Субсидияләр алуга документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы комплектын кертмәү;

хуҗалыкның әлеге Тәртип шартларына туры килмәве.

10. Идарәләр гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә:

бу Тәртипнең 9 нчы пункты нигезендә тапшырылган документларны карый;

күрсәтелгән документлар нигезендә Министрлык раслаган форма буенча Татарстан Республикасы муниципаль районына бирелергә тиешле субсидияләр турындагы җыелма белешмә-исәп-хисапларны тутыра һәм Министрлыкка кертә.

Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы комплектын кертмәү;

хуҗалыкның әлеге Тәртип шартларына туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитыннан акча калмау.

11. Министрлык хуҗалыклар белән Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешүләр төзи.

12. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм акчаны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлекләрендә ачылган шәхси исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелгән җыелма белешмә-исәп-хисаплар бюджет акчасын күчерү өчен нигез булып тора. Бюджет акчасы шәхси исәпләренә күчерелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә Идарәләр субсидияләрне хуҗалыкларның банк исәпләренә күчерә.

13. Бирелгән субсидияләр билгеләнгән субсидияләрдән максатка яраксыз файдалану һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү фактларын ачыклау буенча Идарәнең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләр бирү турындагы килешүләр белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр субсидияләр алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

15. Бу Тәртипнең 13 нче һәм 14 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемнә үз ирекләре белән кире кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

16. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибенең субсидияләр алучылар тарафыннан үтәлешен тикшерүне законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

17. Башкарма комитетлар, Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелә торган документларның һәм хуҗалыклар тапшыра торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә тиешле затларга һәм җитәкчеләргә йөкләнә.

18. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков